Эльмира Шәрифуллина




Шигырьләр, табышмаклар, әкиятләр

КАЗАН ● ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ ● 2009

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5
Ш95

Рәссамы
**Рөстәм Хәбибуллин**

**Шәрифуллина, Э.М.**

Ш95 Баллы балачак : шигырьләр, табышмаклар, әкиятләр / Эльмира Шәрифуллина. – Казан : Татар. кит. нәшр., 2009. – 63 б.
ISBN 978-5-298-01800-5

**Әлеге китапка авторның тормышны җанлы, истә калырлык образлар белән тасвирлаган, йөгерек тел белән язылган, туган илне, табигатьне, тереклекне яратырга өйрәткән, әхлак сабаклары бирүгә нигезләнгән әсәрләре тупланды.**

УДК 821.512.145-1-93
ББК 84(2Рос=Тат)-5

ISBN 978-5-298-01800-5

© Татарстан китап нәшрияты, 2009
© Шәрифуллина Э.М., 2009

# ЯЗ ҖЫЯМ

## Гөл үсә

Безнең бакчада
Матур гөл үсә,
Аны иркәләп,
Җылы җил исә.

## Спортчы тамчылар

Яз җитүгә, тамчылар
Физзарядка ясыйлар.
Иртән, кичен, көндезен –
Сикерәләр көнозын.

Терекөмеш кебекләр,
Күр, нинди йөгерекләр!
Чыккан кебек ярышка,
Ашыгалар финишка.

## «Күзле» кояш

Кояшкаем, туры кара,
Серебезне бүлешик.
Ләкин күзләреңне
күрмим,
Аңларга моны ничек?

Китаптагы рәсемеңдә
Бар иде бит күзләрең.
Ә урамда карап булмый,
Күреп булмый үзләрен.

## Күлләр

Әй күлләре, күлләре –
Алар җирнең күзләре.

Яз буе һәм җәй буе
Керфек какмый яттылар.
Ә салкын кыш
килгән иде –
Күзкәйләрен яптылар.

## Резидә

Резидәкәй зур үскән,
Апасы белән кичтән
Табак-савытлар юа,
Юа да сөртеп куя.

Чыланса да күлмәге,
Яхшы аның теләге –
Өйдә булсын чисталык,
Килә эшкә остарып.



## Әни күзәтеп тора

Тирә-ягым –
мамык юрган,
Йомшак, саф һава.
Яңакларга, керфекләргә
Ап-ак кар ява.

Шау-гөр килә
тау буйлары,
Уйный нәниләр.
Алардан да нык
шатланып
Йөри әниләр.

## Шәһәргә килгәч

Нинди рәхәт, җылы яңгыр
И коя соң, коя соң.
Тамчылары барын бар да,
Болытлары кая соң?

Күзләрен кысып, Дәүли
Түшәмнән болыт эзли.
Душтан болытсыз гына
Вак «яңгыр» сибеп тора.

## Борчаклар

Борчаклар җиргә егылгач,
Кадап чыктым чыбыклар.
Аннан күреп исем китте,
Кара, нинди кызыклар.

Күрегез, күр сез аларны,
Барсы торып утырган.
Куллары юк, ә үзләре
Чыбыкларга тотынган.

Мыеклары белән алар
Чорналганнар шулчаклы.
– Әй, шаян җил, хәзер менә
Егып кара борчакны!

## Чигү җепләре бирик

Иртән торды да
беркөнне
Хәйран калды
Гөлчәчәк –
Тәрәзә пыяласында
Меӊ төрле гөл,
Меӊ чәчәк.

– Әни, – ди ул, –
чәчәкләрне
Ак ситсыга күчерик
Йә булмаса
Кыш бабайга
Чигү җепләре бирик!



## Рәсем дәфтәре

Бу рәсемнәрнең барсын
Ясаган идем үзем.
Бусы – абый, бусы – песи,
Монысы сеңлем –
Гөлйөзем.

Менә тагын өчәү бергә,
Менә монда карагыз!
Барыбыз да үсеп җиткән –
Айга менеп барабыз.

## Яз җыям


Көн кояшлы,
Көн аяз,
Урамда күптәннән яз.
Кичтән үк хәстәр корам,
Иртүк сикереп торам.

Эшем күп,
Юк буш арам –
Ерганакка юл ярам.
Тамчыга чиләк куям,
Чиләгемә яз җыям.

## Гармунда уйныйм

Уйныйм, уйныйм,
Матур җырлар
Агыла да агыла.
Көйләремдә
Чишмә моңы,
Кояш нуры чагыла.

Уйныйм, җырлыйм,
Әтием дә,
Әнием дә кушылсын.
Өебезгә,
Илебезгә
Моңлы,
Нурлы җыр тулсын!



## Шәһәр әтәчләре



Авыл әтәчләре таныш
Фирүзәгөлгә.
Кунакка кайткач,
Ялгызы
Йөрмәде бер дә.

Явыз да соң
күршеләрнең
Әтәче мәгәр.
Фирүзәгөлне йөгертте
Ындырга кадәр.

Шәһәрдә суыра торган
Әтәчләр генә.
Бер-бер артлы
авызыма
Шудырам менә.

Усалланмыйлар,
кумыйлар
Алар беркемне...
Шулай да шәп
сикерттеләр
Фирүзәгөлне.

Капкан иде, үрә торды
Кызның чәчләре.

Теш төбен шундый
тешләде
Шәһәрнең кычкырмый
торган
Шук «әтәчләре»!

## Үсәм икән



Арыш ипиен зур кабып
Ашасам – үсәм икән.
Ботка белән аш яратсам –
Йокыны бүсәм икән.

Алма, салма, суган,
шалкан –
Һәммәсе дә үстерә.
Сөт, эремчек, катык,
әйрән
Үсәремә көч бирә.

Бик зур булып үсәм икән
Күп итеп йоклаганда,
Дөбер-шатыр сикерүдән,
Шашудан туктаганда.

Зурлар сүзенә
катнашмый,
Эндәшмичә торсам да,
Үсәм икән күп йөрсәм дә
Һәм дә тик утырсам да...

# АК ҖИЛ

## Сеңлемнең теләге

Минем сеңлем Энҗенең
Укырга теләге зур.
«Төшемдә дә күрәм, – ди ул, –
Кара такта һәм акбур».

«Укыйм, – ди ул, – «бишле»гә,
Алмыйм, – ди, – бер «берле» дә.
Укырлык булгач «берле»гә,
Ник мәктәпкә йөрергә?»

## Ак җил

Ак җил булмый, дисезме?
Кыш көне җил ак була.
Табигатьтә иң матур
Һәм иң гүзәл чак була.

Ак җилләр, ак бураннар
Тәрәзәгә кар сибә.
Тышка чакырып чыгара
Һәм бит очыннан «үбә».

Кочагына кар төяп,
Ак каеннарны бөгә.
Шатлыгыннан сызгыра,
Бии, очына, чүгә...

Кыш бабайны, Кар кызын
Ак җилләр алып килә.
Һәрбер илгә, һәр өйгә
Яңа ел булып керә.

Ак җил булмый, дисезме?
Кыш көне җил ак була.
Җилләр ак булган өчен,
Кыш иң сылу чак була!



## Уза идем Илшатны

Әй әйләнә карусель,
Йөгереп килде дә
Марсель
Атланды Тимеркүккә,
Очып китмәкче күккә.

Чаптыра атын егет,
Алдында дустын күреп.
«Җитәм, куып җитәм, –
ди, –
Хәтта узып китәм, –
ди, –

Әйдә, әйдә, малкаем,
Үзең тап шунда җаен.
Узыйк, узыйк
Илшатны,
Алдагы җирән атны».

Оча гына Тимеркүк,
Даладагы җилләр
күк...
«Уза идем, – ди, –
Марсель, –
Туктамаса карусель».

## Мин монда

Кем бар анда?
Тук-тук-тук.
Сәйдәш качты,
Сәйдәш юк.

Күренмидер кулы да,
Күренмидер аягы,
Сәйдәшебез кая киткән?
Әлеге дә баягы
Монда калган таягы.

Куяны да биредә,
Аюлары, керпесе,
Кызыл күзле төлкесе.
Һәммәсе дә сорыйлар:
– Сәйдәш абый кайтмаса,
Китәбез, – дип елыйлар. –

Сәйдәш абый булмагач,
Күңелсез безгә, – диләр, –
Качкан җиреннән чыкса,
Калабыз сездә, – диләр.

Ишек шакый
Кем анда?
Сәйдәшебез
Юк монда...

Менә шулай такмаклап,
Качышлы уйный идек,
Ишек, пәрдә артыннан
Сәйдәшне эзли идек.
Нәни аяк-кулларны
Күреп тә күрми идек,
– Мин монда, – дип, ялт итеп,
Сәйдәш тә чыкты килеп...

## Яңгыркаем, каенкаем

Яу, яу, яңгыркаем,
Тизрәк үссен каенкаем,
Минем кадәр булсын ул!

Яу, яу, яңгыркаем,
Тизрәк үссен каенкаем,
Буй-сыны булсын сылу.

Тукта, тукта, яңгыркаем,
Узып китте каенкаем
Былтыр ук инде мине.

Тукта, тукта, каенкаем,
Миңа да бит, яңгыркаем,
Тизрәк үсәсе иде!

## Ике әбәк, өч әбәк

*(«Мәче белән тычкан» уены өчен)*

Әбәү, әбәк,
Бер әбәк,
Ике әбәк,
Өч әбәк –
Әбәк, әбәк, әбәнәк,
Син – озын, бу – тәбәнәк.

Әбәү, әбәү,
Кем соң бу?
Яшел күлмәк кисен бу,
Йөгереп кенә йөрсен бу,
Урталыкка керсен бу.

Урталыкка кем керде?
Кайда мәче?
Кем күрде?
Тычкан булсын елгырлар,
Елгырлар тоттырмыйлар...

Әбәү, әбәк,
Бер әбәк,
Ике әбәк,
Өч әбәк –
Уен өчен бер сәбәп,
Син – озын, бу – тәбәнәк!..



## Тәмлетамак Нәркис

Ярата безнең Нәркис
«Барбарис», «Тузик»,
«Кис-кис».
Көне буе суыра,
Шул көе дә шудыра.

– Сәбәбе нәрсә, Нәркис,
Бик яратасың «Кис-кис»?
– Ашасам күбрәк
«Кис-кис»,
Зур үсәрмен, – ди Нәркис.

Теләге үсү икән,
Үскәч ни кылыр микән?..
Елмаеп әйтә Нәркис:
– Күбрәк ашармын
«Кис-кис».

## «Күгәрчен сөте»*

– Тешләреңне сакла,
кызым,
Конфетка якын килмә!
– Тимим әби, бирче,
зинһар,
«Күгәрчен сөте»н генә.

* «Күгәрчен сөте» – конфет исеме (рус телендә: «Птичье молоко»).

## Кемнәр җитез?

Кемнәрнең күзе очлы,
Әйдә, уйныйк качышлы.

Кем җитез, өлгер, зирәк,
Моны белү бик кирәк.

Без саныйбыз йөзгәчә,
Тагын йөз дә бергәчә.

Санныйбыз такмак әйтеп,
Салмак, аннан тиз әйтеп.

Сез күзәтеп торыгыз,
Кемдә туктар кулыбыз? –

Шул кеше сакта тора,
Ялкау булса, оттыра.

Уеныбыз – качышлы,
Бер йөгереп алышлы.



## Әкият үзе килә

Кыймылдарга
            куркып торам,
Карыйм тирә-ягыма.
Киенгәне юкамы?
                        Җир
Һаман юрган ябына.

Чат ябышып,
            җепшек карлар
Ява гына җиремә.
Җем-җем көлә
            тирә-ягым,
Аклык керә илемә!

Кышкы урман.
Тирә-юнь пакь,
Ап-ак кар
            җем-җем көлә.
Әллә шуып, әллә йөзеп,
Әкият үзе килә.

## Фасылларның асылы

Кыш җиттеме, җиргә төшә
Ак болытлар мамыгы.
Мамык юрганга төренә
Игеннәрнең тамыры.

Яз җитүгә, җирне сыйлый
Күк болытлар яңгыры.
Тулып кала коеларның
Шифалы су сандыгы.

Җәй булып та, көз булып та
Килә ел фасыллары.
Кадерле дә, кирәкле дә
Фасылның асыллары.

## Өмә

Кардан ачылгач урамнар,
Яланнар, өй яннары,
Себереп түгәләр иң элек
Кыш җыелган чүп-чарны.

Яшел чирәм иркен сулап,
Матур булып үссен дип,
Шул матурлык күңелләргә
Һәм эшләргә күчсен дип,

Җыр тусын дип матурлыкка,
Чисталыкка сокланып,
Җирнең йөзен нурлау өчен
Өмәгә чыга халык.

## Серле дулкыннар

Җитез җилләр
Көй уйныйлар,
Ә дулкыннар бииләр,
Бииләр парлап, күбәүләп,
Кара, нинди җиллеләр!
Кул чабалар яр буенда
Үзләренә-үзләре,
Серле иткән дулкын икән
Бу олы диңгезләрне...

## Әкиятләр яратам

Әкиятләр нинди була?
Әкияттә – батырлар.
Бар бит анда
Ак аюлар,
Көчле
Камыр батырлар.

Әкиятләр нинди була?
Әкияттә – шаяннар.
Йөгерешә
Җилаяклар,
Чакмый торган
Чаяннар.

Әкиятләр нинди була?
Әкиятләр – хәйләле.
Чөнки анда зирәк
Былтыр,
Су анасы, Шүрәле...

Серле, кызык
әкиятләрне
Тыңларга бик яратам.
Әти әкият сөйләсә,
Шундук
йокларга ятам.





## Мәчем йоклый

Песи, песи, пескәем,
Ник ялтырый күзкәең?
Мыраулыйсың үзкәең,
Шулмы синең сүзкәең?

Песикәем, пес-пес,
Иркәләнеп үс-үс,
Куеныма пос-пос,
Мәчем йоклый, тс-тс!

Песием, иркәбаем,
Эриме әллә маең?
Күләгәгә качкансың,
Бер күзеңне ачкансың.

Мыраулыйсың:
мыр-мыр,
Ай-яй матур җыр-җыр.
Сине бик яратабыз,
Шуны белеп тор-тор.

Күзкәйләрең зур-зур,
Мыекларың зыр-зыр,
Күселәрне үрчетмә,
Ауга әзер тор-тор!



## Җитәкләшеп җил белән

Җитәкләшеп җил белән
Чабабыз да чабабыз.
Куып җитәрсез микән,
Ягез, сынап карагыз.



Куыгыз, ку –
Барыбер
Тоталмассыз тиз генә.
Чөнки без йөгерәбез
Җитәкләшеп җил белән!..

Тоттык, димсез, чапсаң да
Җитәкләшеп җил белән.
Юк, тоттырмый идем мин,
Туктап калды җил генә.



# БАЛЛЫ БАЛАЧАК

## Кояшлы табын

Иртәнге табын янында
Кашык, касә, тәлинкә.
Уртага чәчәк куелган,
Барсы нурга коенган.

Кояш уйный тәрәзәдә,
Бии өстәл өстендә.
Кояш минем битләремдә,
Коена чәем эчендә,

Сөлге, ашъяулык
чугында,
Әниемнең йөзендә.
Кояш – туган ил күгендә,
Кояш – табын түрендә!

# Нәни музыкант

Сандугачлар сайрашамы,
Бал корты безелдиме –
Дәфтәремә язып куям
Откан бер яңа көйне.

Яфракларның бар үз җыры,
Тыңлап торам, таң калып.
Челтер-челтер чишмә ага.
«Си-ля-соль», –
дим, шатланып.

Җилләр исә: «До-ре-ми-фа»,
Яңгыр ява: «Соль-ля-си», –
Менә тагын өр-яңа җыр,
Менә тагын яңа көй.

Көчек шыңшыган буламы,
Энем елыймы өйдә?
Тирә-юньдә күпме тавыш –
Барсын салам мин көйгә.

## Җилләр, җилләр



Бу җилләр ничә
төрле соң?
Көчле һәм талгын,
диләр.
Әче, диләр, тозлы,
диләр –
Гайрәт, тәм билгелиләр.

Каты, диләр, йомшак,
диләр,
Әйтерсең капшап була.
«Фирүзә җил юлдаш
булсын!» –
Дип, әби дога кыла.

Бу җилләр ничә
төрле соң?
Җылысы, салкыны бар.
Җир себереп
искәннәре –
Җәяүлесе ташый кар.

Бу җилләр ничә
төрле соң,
Ничә исемдә алар?
Җилнең эшен, төсен,
көчен
Санап чыгып кара,
бар...

## Иң матур әни

Минем әни бу дөньяның
Иң чибәре, сылуы.
Нинди бәхет
Һәр баланың
Үз әнисе булуы!
Минем әни, һич бәхәссез,
Иң сөйкемле әни ул!
Әйткән сүзе,
Кылган эше –
Һәммәбезгә туры юл.
Борчыйсым килми әнине,
Елмаеп,
Көлеп йөрсен.
Иң матур әни икәнен
Бөтен дусларым күрсен!

## Җәяүле буран

Аяклары күренмәгәч,
Ышанмый идем бер дә.
Юри буран көнне чыктым
Чаңгы киеп
Йөрергә.
Тау итәгенә җитәрәк
Арыды,
Күреп торам.
Әкренәйде,
Туктап калды,
Җәяүле икән буран...

## Әгәр дә мәгәр...

Әгәр дә мәгәр
Мин әни булсам,
Кызларым бик күп
Булырлар иде.
Тегеп тә чигеп,
Юып та җыеп,
Гел ярдәм итеп
Торырлар иде.

Сөембикәдәй
Сылу, сөйкемле,
Туган халкыма
Сүзе үтемле,
Олы йөрәкле
Ана иттереп
Бирер идем күп
Кызлар үстереп,
Әгәр дә мәгәр
Мин әни булсам!..

Әгәр дә мәгәр
Мин әти булсам,
Улларым бик күп
Булырлар иде.

Уңган да булган,
Эшчән улларым
Кояштан иртә
Торырлар иде.

Бәхтияр кебек
Кыю йөрәкле,
Туган иленә
Һәрчак кирәкле
Сөлектәй уллар
Үстерер идем,
Батыр булырга
Көч бирер идем,
Әгәр дә мәгәр
Мин әти булсам!..

## Уйныйбыз

Без уйныйбыз.
Ак кар төшә,
Төшә дә иңгә ята.
Оеп кына ява-ява,
Болыттан җеп
сава-сава,
Туннарга
«тегә» яка.

Иңебездә – ап-ак яка,
Җиңнәрдә – ак беләзек.
Ак кар белән кибет салып,
Ак алмалар сатып алып,
Ак кар белән түләдек.

Ак кар белән
койма тоттык,
Капка куйдык ак кардан.
Бозлы, тайгак юллар үттек,
Юл-сукмакка
ком-таш сиптек,
Ташып чишмәле ярдан.

Уйныйбыз,
Һаман уйныйбыз,
Ап-ак кар иңгә ята.
Оеп кына ява-ява,
Болыттан җеп сава-сава,
Туннарга «тегә» яка.

## Үзебез дә гөлләр кебек

Гөлләремә сулар сибәм –
Сулышлары киңәйсен.
Якты көн, кояш алдында
Чәчәк атсын, ирәйсен.

Чәчәк атсыннар гөлләрем,
Ямь кертеп өебезгә.
Бербөтен зур гаилә булып
Яшәргә язсын безгә.

Чәчәк кебек якты булып
Ачылсын күңелебез.
Бер савытта үскән алсу
Гөл кебек һәрберебез!



## Шофёр буласым килә

Үскәч кем буласың, дип
Сорыйлар да сорыйлар.
Әллә нинди һөнәрләр
Саныйлар да юрыйлар.
Теләгем шундый
минем –
Шофёр буласым килә.
Капка төбенә кайтып,
«Җырлап» торасым
килә:

– Пип, пип, пип,
Мин бу, мин...
Кем бар анда, кайсыгыз?
Чыгып капка ачыгыз!
Юл өстендә тормагыз,
Юлдан читкә качыгыз!

Юллар үтәсем килә,
Ерак китәсем килә,
Сөт, суганын калага
Төяп илтәсем килә.
Авыл күчтәнәче бу
Әби, бабай, малайга,
Юлда тыз-быз йөрсәләр,
Кычкыртамын алай да:

– Пип, пип, пип,
Кит син, кит...
Кычкыртам иплəп кенә,
Атлагыз читләп кенә,
Олы юлга кермәгез,
Карамыйча йөрмәгез!

## Ата каз

Күргәнегез бармы сезнең
Ата каз биегәнен,
Нәни бәбиләре чыккач,
Кычкырган, сөенгәнен?

Ул каңгылдап, әнкә казны
Яратып сөйләшкәнен,
Сары йомгак бәбкәләргә
«Таң-таң» дип эндәшкәнен?

Таң атты дип шатланса да,
Юаш икән бу, димә:
Ата каз булганда, берүк
Бәбкә янына килмә.

## Илем минем

Илем минем Татарстан –
Әтиемнең туган җире,
Бу җир минем әниемнең,
Бабамнарның торган иле.

Мин бу җирдә тәпи бастым,
Мин – бу җирнең хуҗасы.
Мин бу җирдә көн итәсе,
Шушы илдә торасы.

Бу җир минем улларымның,
Кызларымның иле булыр.
Туган җиреңне яратсаң,
Тормыш сыйлы, көйле булыр.

Туган җир сине олылар,
Син олы итсәң генә.
Бәхет килә, кешеләрне
Бәхетле итсәң генә.

Газиз илем Татарстан –
Нәселемнең туган җире,
Җиде буын бабамнарның
Гомер иткән, торган иле.

Мин бу җирдә тәпи бастым,
Мин – бу җирнең хуҗасы.
Мин бу җирдә көн итәсе,
Шушы илдә торасы.

Бәхет килә, кешеләрне
Бәхетле итсәң генә.
Туган җир сине олылар,
Эз салып китсәң генә.

## Дуслык, чын дуслык!

Иптәшләрең әйбәт булса,
Кыскара озын юл да.
Бергә булыйк, бердәм булыйк,
Дуслыкның көче шунда.

Киңәшле эш һич таркалмас,
Куллар көч бирсен кулга.
Бергә булыйк, бердәм булыйк,
Дуслыкның көче шунда.

Ярдәмләшеп, җырлап-көлеп
Яшик кояшлы елда.
Бергә булыйк, бердәм булыйк,
Дуслыкның көче шунда.

Юлдаш булып йөр, дуслык,
Илче булып кил, дуслык,
Һәрбер өйгә кер, дуслык,
Безнең белән тор, дуслык,
Дуслык, дуслык, чын дуслык!

## Килегез, кунак булырсыз

Килеп җиттек балачакның
«Җәй» дигән аланына.
Йөгерә-йөгерә сулар сиптек
Миләше, баланына.

Эш беткәч, уйнарга ярый –
Сикерәмен, күрегез.
Килегез, кунак булырсыз,
Иркен күңел түребез.

Серле сын ясап бирермен
Беләсезме нәрсәдән? –
Кул-ботаклы агачым бар
Җил сындырган кәүсәдән.

## Баллы балачак

Балдан татлы балачагым,
Күпме хисләрем синдә,
Күпме иркәләү, сөелү,
Күпме җылы кул иңдә.

Шул кулларның
кайнарлыгы
Иңнән йөрәккә иңгән.
Теләк, киңәш-табышлары
Аңга һәм канга сеңгән.

Балдай татлы балачакта
Җир җиләкләре тәме.
Балдай балачагым өчен
Рәхмәт, Туган ил, яме!

## Елмаегыз, көлегез

Елтыр-елтыр елтырыйм,
Челтер-челтер челтерим,
Ерганак мин, кар суы,
Елгага агам туры,
Елларга агам туры.

Җыр башладым, тыңлагыз,
Юк, кушылып җырлагыз.
Дәртле, дымлы яз иңемдә –
Моңаешып тормагыз,
Бии-бии җырлагыз.

Йөгерегез, көлегез
Һәм челтери белегез.
Хәтта кояшсыз көндә дә
Сез елтырый белегез,
Сез елмая белегез!

# КЕМ? КАЙДА? НӘРСӘ? НИЧЕК?

## Ул нәрсә?

Әллә ничә иренле,
Теше дә әллә ничә,
Ярты басу арышын
Ашап бетерде кичә.

*(Комбайн)*

## Нинди җиләк?

Эре җиләк,
Зур җиләк,
Иртә – чиләк,
Кич – чиләк,
Олыларга да кирәк,
Балаларга да кирәк,
Нинди җиләк
Ул, димәк?

*(Виктория)*

## Бу нинди бизәк?

Ак һәм кара төсләре,
Тик күренми җепләре,
Матур булсын дип безгә,
Әнә уңга да сулга
Челтәр сузганнар юлга.

Шакмаклап, пөхтә итеп,
Чәчәкләрен күп итеп,
Җәеп салып асфальтка
Кем соң бизәк төшергән,
Юлны чигеп бетергән?

Челтәр-чигүне күзләп,
Сорауга җавап эзләп,
Торам койма буенда.
Юлда яткан матурлыкның
Серен ачу уемда.

*(Челтәрле коймадан
төшкән күләгә)*

## Мөгридер, мулыйдыр

Мөгридер ул, мулыйдыр,
Койрыгын да болгыйдыр,
Сөт, эремчек, мае белән
Һәммәбезне сыйлыйдыр.

*(Сыер)*

## Бәлки, җавап бирерсез?

Ләйлә чыкты урамга,
Сәйдә чыкты урамга.
Сәйдәнең көрәге бар,
Ләйләнең чиләге бар.

Ләйлә уйный комлыкта,
Сәйдә уйный комлыкта,
Тик бергә уйнамыйлар,
Тик бергә уйламыйлар.

Ләйлә уч белән комны
Тутыра чиләгенә,
Сәйдә көрәге белән
Тутыра күлмәгенә.

Ләйләнең кулы кара,
Ә Сәйдәнең – итәге.
Уйнадылар,
                    уенның
Булмады һичбер тәме...
Бәлки, җавап бирерсез,
Уенның кайда яме?

*(Бергә уйнауда,*
*тату булуда)*

## Муены – гәүдәсе буе

Хәтта иң биек агачның
Яфрагын ашый ала.
Муены – гәүдәсе буе,
Теләсәң, үлчәп кара.

*(Жираф)*

## Күңелендә юк баю

Урманында ул патша,
Кыш көне кардан аста.
Уенда юктыр баю,
Балны ярата (...).

*(Аю)*

## Уйланыгыз!

Сезгә сорау бирим әле,
Булат, Марат, Гөлгенә:
– Әнкәегезнең кадерен
Беләсезме гел генә?

Йомыш кушса, иренмичә,
Турсайтмыйча иренне
Эшлисезме?
...Кызартты бит
Сорау Гөлназ, Сиринне.

Уйлыйк әле,
Нигә һәрчак
Әниләр көлеп йөрми?
Димәк, безнең кайберебез
Әни кадерен белми.

## Нишлисез?

Мин шомырт агачымын,
Ап-ак чәчәкләр атам.
Тәмле хуш ис таратам,
Балаларны яратам,
Олыларны яратам.

Ямь бирәм,
Җимеш бирәм,
Сыйлыймын сезне ел да.
Тик...
Яз җитсә, ерткычлык –
Ботагым сезнең кулда.

И балалар, балалар,
Белә торып нишлисез?
Аш биргәнгә таш атып,
Яман эшләр эшлисез:

Яз аласыз сындырып,
Күз җыясыз сындырып –
Җимешле агачларга
Булырмы бер тынгылык?..

# ЧЫК-ЧЫК ИСЕМЛЕ ЧЫПЧЫК

## Чык-Чык исемле чыпчыкның зоопарк иленә сәяхәте

*(Әкият)*



Ерак түгел, якында,
Кабан күле артында
Яшәгән нәни чыпчык,
Исеме булган Чык-Чык.

Канат чыгу белән ул
Зоопаркка тоткан юл.
Күңелле монда бик тә,
Чык-Чыкның
исе киткән.

Дус яши **попугайлар**,
**Лачыннар** һәм
**тургайлар**.
Бер савыттан эчә сөт
**Арыслан**, **бурсык**
һәм **эт**.

**Ябалак**, **челән**, **торна** –
Һәркайсы, һәркем монда
Үз эше белән мәшгуль,
Үз эше белән мәшһүр.

Ерак тайгадан килгән,
Буй-буй шома тун кигән.
Йөренә әрле-бирле,
Соң, шул юлбарыс инде.

Тавышын сыный гүя –
Кычкыргалап та куя.
Йә бик усал, гайрәтле,
Йә бик юаш, әйбәт ул.

Туны калын, туны ак,
Төньяктан килгән кунак,
Су чәчрәтә, су керә,
Ятсынып тормый бер дә.

«Мин булам, – ди, – ак аю,
Саумы, нихәл, агаем!..»
Исәнләшә изәп кул
Көрән аю белән ул.

Көрән аю: «Туган, – ди, –
Чык инде, чык судан, – ди, –
Тыңлыйк, – ди, – ятып кырын
Шук попугайлар җырын...»

Калды соры бүреләр...
Чү! Нинди ут күренә?
Чык-Чыкка булды көлке –
Ут төсле, имеш, төлке.

Койрыгын җилләр тарый,
Күзләре бик мут карый,
Чык-Чыкка гүя дәшә:
«Әйдә, кер, миндә яшә!»

Олы да соң, дәү дә соң,
Тау чаклы бар гәүдәсе:
Аяклары – бүрәнә,
**Фил** дигән кунак әнә.

Туктаусыз тора биеп,
«Саумы», – дип,
башын иеп,
Чык-Чыкны
сәламли ул,
«Шәрыктән сәлам!» –
ди ул.

Филдән соң Чык-Чык
белән
Исәнләште **күк болан**,
Исәнләште
**маймыллар**
Һәм яшькелт
**крокодиллар**.

Киртләчләре өстенә,
Өркәчләре өстенә,
«Аргансың», –
дия-дия,
Утыртып йөрде **дөя**.

Дәшеп тора **кыргый ат**,
Зур мөгезле **кыргый як**.
Чык-Чыкка
шундый кызык,
Өлгерсен генә очып.



Диңгез артыннан килгән,
Энәле күлмәк кигән,
Керпе төслерәк бераз,
Шушы икән **дикобраз**.

Үзләре канатлылар,
Очарга яратмыйлар,
Алтынсу каурыйлары –
**Тавис кошы** болары.

Әйтте болан баласы:
«Кая очып барасың?
Уйныйк, Чык-Чык, куышып,
Уйныйк, – диде, – узышып».

**Бөркет** булып бөркет тә
Ачуланмый бөртек тә.
Йөрде Чык-Чык таң калып,
Гаҗәп ил бу зоопарк!

## Ала карга

*(Әкият)*

Борын-борын заманда,
Бер сүз инде һаман да:
Йоклатканда
курчакны,
Сибеп кенә
борчакны –
Әкият сөйлим сезгә,
Яңа җыр
көйлим сезгә.
Борын-борын заманда,
Әби бәби булганда,
Бабай нәби булганда,
Каргалар ак туганнар.

Көннәрдән бер көн
болар,
Шаулап акканда
сулар,
Җыелганнар
киңәшкә –
Бер ялгыз, ике әшнә
(Ялгызы – бала карга,
Әшнәләр –
парлы карга):
– Исемебез –
Ак Карга,
Өс-башыбыз ак –
бар да,



Ак кием акланмый һич,
Ак кием сакланмый һич,
Ак килешми каргага,
Тиз таплана, карала,
Аннан чыш-пыш тарала:
Каргалар, имеш, шакшы,
(Башкалар гына яхшы!)
Өстенә карап бакчы,
Өстенә карап бакчы...
Керле булып йөргәнче,
Таплы күлмәк кигәнче,
Мандырыйк без өс-башны,
Буятыйк керфек-кашны...

Сүз алган икенчесе,
Кыяфәткә көчлесе,
Як-ягына каранган,
Мондый фикер аңардан:
– Кара төс әйбәт булыр,
Буебыз зифа торыр,
Кара Карга, диярләр,
Кара – матур киярга.

– Юк, – дигән Бала Карга, –
Мин кара төс яратмыйм.
Буятам кызыл төскә,
Очып менәм дә өскә
Кып-кызыл карга булып,
Сайрыймын талга кунып...

Өлкәннәр – ике әшнә:
– Бирелмә, – дигән, – хискә,
Карга кызыл буламы?
Уттай янып торамы?
Башка төсне сайла син,
Табигатькә җайлан син.

Уйланган Бала:
– А-лай?..
Зәңгәр төс булыр кулай.
Очып күккә менгәндә,
Күренмәм беркемгә дә.
Су буена килгәндә,
Күл кырында йөргәндә,
Табалмас мине дошман.
(Сакланмак кирәк дустан.)

Уйнап йөргән кызларның
Тәтиләрен урлармын,
Кайда нәрсә ялтырый –
Шунда очып кунармын.

Өлкәннәр аннан көлгән:
– Бала-чага шул, – дигән. –
Юк-барга кызыгасың,
Шакшыда казынасың,
Теләсә ни чүплисең,
Шуңа, ахры, үсмисең?

Күпне күргән каргалар
Аны шулай тиргәгән:
– Юкса үзең бик җитез,
Бер җирең юк килмәгән!..
Ахырдан әйткән әшнә:
– Үзең теләсәң нишлә,
Зәңгәргә кул куялмыйм,
Мин зәңгәргә буялмыйм!

– А-лай-са, – дигән Бала, –
Яшел төсне сайлыйк без.
Яшел агачка кунсак,
Яшел чирәмдә торсак,
Яшел күлмәкле булсак,
Күрмәс безне беркем дә.
Курыкмабыз бер көн дә,
Яшел карга булырбыз,
Яшел җирдә торырбыз.

Яшел-яшел, ямь-яшел
Күлмәгебез-тунныбыз.

Тамак кыра зур Карга,
Тын кала шунда бар да:
– Озын сүзнең кыскасы,
Табыйк эшнең остасын.
Буяучыга барыйк без,
Серне ачып салыйк без,
Төсләрне ул шәп белер,
Дөрес киңәшен бирер...

Шушы фикерне җөпләп,
Кузгалган болар иплэп.
Буяучыга киткәннәр,
Озын юллар үткәннәр,
Бик күп сулар эчкәннәр,
Елга-күлләр кичкәннәр,
Бер карышка күчкәннәр.

Очканнар бергә-бергә,
Аннан төшкәннәр җиргә,
Җилләр белән көрәшеп,
Яңгыр белән серләшеп,
Бераз арып, чирләшеп.
Бара торгач,
Шул заман
Пәйда булган зур алан.
Ул Кояшка манчылган,
Күзге тора – тамчыдан.

Чәчәкләр аллы-гөлле,
Яктыртып бөтен көнне
Елмаялар, көләләр,
– Хуп, –
дип, сәлам бирәләр, –
Хуш киләсез, әйдәгез,
Җәйне бездә җәйләгез!

– Рәхмәт, –
дигән каргалар, –
Җәйләгән чак булгалар.
Хәзер вакытыбыз тар,
Бик зур йомышыбыз бар,
Мондый йомыш бик сирәк,
Безгә Буяучы кирәк.
Ярдәм италыр кемнәр?

Юлны өйрәткән гөлләр:
– Үтәрсез сазлы күлләр,
Аннан уңга китәрсез,
Карамага җитәрсез,

Югарыга карагыз,
Тәрәзәсен санагыз.
Өч тәрәзә, бер ишек,
Түбәсендә ун тишек –
Шунда тора Буяучы,
Туктый аңа юлаучы.

Рәхмәт әйтеп, каргалар
Сазлыкка юл алганнар.
Куе үлән арасыннан,
Сулы сазлык
карасыннан
Барганнар да барганнар,
Барганнар да барганнар.

Караманы тапканнар,
Тәрәзәсен какканнар:
– Бармы анда берәрсе?
Килә иде күрәсе.

Ачылып киткән ишек,
Биек баскычтан төшеп,
Килеп чыккан Буяучы:
– Кем ул мине сораучы?

Сәлам биргән каргалар,
Хәл-әхвәл сораганнар.
Каршысына басканнар
Һәм серләрен ачканнар:



– Ак күлмәк тиз карала,
Ак килешми каргага,
Ак карга булып йөрү –
Гүя үзеңнән көлү.
Ак карга булып йөрү –
Гүяки күзгә керү...
Тыңласаң иде сүзне,
Буясаң иде безне.
Кайсы буявың яхшы,
Кайсы буяу килешле?
Безнең килбәт-йөрешне
Нинди төс нәфис итәр?
Нинди төс күркәм итәр?
Сиңа тапшырдык эшне, –
Дигән парлы каргалар.
Әйткән Бала Карга да:
– Фикереңне сорыйбыз,
Киңәшеңне тыңлыйбыз.
– Әйтәм, – дигән Буяучы, –
Киңәшем минем мондый,
Буявым бар, шәп шундый.

Бүлдергән Бала Карга:
– Нинди төс,
Әйтеп кара?!

– Кара буяу,
Кап-кара!
Кара төс сезгә бара.
Гәүдәгез ыспай булыр,
Җемелдәп кенә торыр…
– Ка-ра? –
дигән Бала Кош,
Авызларын күптергән.
– Бара! –
дигән Ата Кош. –
Ул дөньяны күп күргән.
– Риза, –
дигән Ана Кош, –
Ыспай буласым килә…

Киреләнеп торса да,
Бала Карга да күнә.

Куллар сугып
килешкәч,
Эш башлаган Буяучы:
– Кара төсне, дусларым,
Бик күп аны сораучы.
Әле бәхетегезгә
Буяу алган чак иде.



Озакламый өлкәннәр
Чем-кара күлмәк киде.

Чират – Бала Каргага,
Ә ул ялт-йолт карана.
Буяганда күлмәген,
Түкте буяу чүлмәген.

– Аһ, – иттеләр өлкәннәр,
– Их, – диде Буяучы да, –
Тагын нәүмиз калды инде
Кара төс сораучылар…

Ала-кола булып калдың
Инде менә үзең дә.
Бу бәланең бөтенесе
Килеп чыкты үзеңнән.
Тик тормавың аркасында
Күрәсең күпме җәбер.

Буялып бетмәде туның –
Ала карга син хәзер...

– А-ла? – диде каргалар.
– Ала! – диде Буяучы.
Ала-кола булып калды,
Бөтерчек – тик тормаучы –
Сабак алсын тыңлаучы!..

Димәк, йомгак, балалар:
Тик тормаган каргалар,
Тыңламаган балалар,
Әййем, юк ла, каргалар –
Ала булып калганнар.

Әкият шунда беткән,
Сөйләдем аны күптән.
Ишеттең син дә бүген,
Яктырсын күңел күгең!

# Эчтәлек

## Яз җыям

Гөл үсә ........................................ 3
Спортчы тамчылар ........................................ 3
«Күзле» кояш ........................................ 4
Күлләр ........................................ 4
Резидә ........................................ 5
Әни күзәтеп тора ........................................ 5
Шәһәргә килгәч ........................................ 6
Борчаклар ........................................ 6
Чигү җепләре бирик ........................................ 7
Рәсем дәфтәре ........................................ 8
Яз җыям ........................................ 8
Гармунда уйныйм ........................................ 9
Шәһәр этәчләре ........................................ 10
Үсәм икән ........................................ 11

## Ак җил

Сеңлемнең теләге ........................................ 12
Ак җил ........................................ 12
Уза идем Илшатны ........................................ 14
Мин монда ........................................ 15
Яңгыркаем, каенкаем ........................................ 16
Ике әбәк, өч әбәк ........................................ 17
Тәмлетамак Нәркис ........................................ 18
«Күгәрчен сөте» ........................................ 18
Кемнәр җитез? ........................................ 19
Әкият үзе килә ........................................ 20
Фасылларның асылы ........................................ 21
Өмә ........................................ 21
Серле дулкыннар ........................................ 22

Әкиятләр яратам ............................ 23
Мәчем йоклый ................................ 24
Җитәкләшеп җил белән .................. 25

## Баллы балачак

Кояшлы табын ................................ 26
Нәни музыкант .............................. 27
Җиләр, җиләр ................................ 28
Иң матур әни ................................ 29
Җәяүле буран ................................ 29
Әгәр дә мәгәр... ............................ 30
Уйныйбыз ...................................... 31
Үзебез дә гөлләр кебек .................. 33
Шофёр буласым килә ..................... 34
Ата каз .......................................... 35
Илем минем ................................... 36
Дуслык, чын дуслык! ..................... 37
Килегез, кунак булырсыз ................ 38
Баллы балачак ............................... 39
Елмаегыз, көлегез ......................... 40

## Кем? Кайда? Нәрсә? Ничек?

Ул нәрсә? ...................................... 41
Нинди җиләк? ................................ 41
Бу нинди бизәк? ............................. 42
Мөгридер, мулыйдыр ...................... 42
Бәлки, җавап бирерсез? ................. 43
Муены – гәүдәсе буе ....................... 44
Күңелендә юк баю .......................... 44
Уйланыгыз! .................................... 45
Нишлисез? ..................................... 46

## Чык-Чык исемле чыпчык

Чык-Чык исемле чыпчыкның зоопарк
иленә сәяхәте *(Әкият)* ..................... 47
Ала карга *(Әкият)* ............................ 51

Литературно-художественное издание

Для детей дошкольного
и младшего школьного возраста

**Шарифуллина** Эльмира Мухаметовна

**Сладкое детство**

Казань. Татарское книжное издательство. 2009

На татарском языке

Әдәби-нәфис басма

Мәктәпкәчә һәм кече яшьтәге мәктәп
балалары өчен

**Шәрифуллина** Эльмира Мөхәммәт кызы

**Баллы балачак**

Мөхәррире *Л.М.Шәехов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Х.Хәсәншин*
Техник мөхәррире һәм компьютерда
биткә салучысы *А.С.Газизҗанова*
Корректоры *Л.Р.Галимова*

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 28.12.2009.
Форматы $60 \times 90^{1}/_{16}$. Басма табагы 4,0.
Тиражы 2000 д. Заказ О-14.

Татарстан китап нәшрияты ДУП. 420111. Казан, Бауман урамы, 19.
**http://tatkniga.ru E-mail: tki@tatkniga.ru**

Оригинал-макет Jaһat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы ААҖ.
420066. Казан, Декабристлар урамы, 2.